**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ МАСАДИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
423753, деревня Масады,
ул. Нефтяников ,дом 18 ,
Тел. 3-44-49

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ МЭСЭДЕ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423753, Мэсэде авылы,
Нефтяниклар ур.,18 нче йорт.
Тел. 3-44-49

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**25 ноябрь 2024 ел** **№3**

**Мәсәде авыл җирлегенең Мәсәде торак пунктында узара салым кертү һәм куллану буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 ноябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, 56 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 21 ноябрендә Мәсәде авыл җирлегенең Мәсәде авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: "2025 елда Актаныш муниципаль районының Мәсәде авыл җирлегенең Мәсәде авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ яшьтәге гражданнан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, 1 төркем инвалидлар, хәрби хәрәкәттә катнашучы гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге формада укучы студентлардан тыш, түбәндәге эшләрне башкаруга 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы:

1. Су белән тәэмин итү системаларын, төзүне һәм ремонтлауны һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су үткәрү челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау, суны анализлау).
2. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен тоту һәм ремонтлау);

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (хуҗасыз йортларны сүтү, агачлар кисү, массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерү).

4.Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау).

«риза» - 97, "каршы" - 0, "тоткарланучылар" -0

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 186 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар -97.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"риза" позициясе өчен 97 граждан тавыш бирде;
"каршы" позициясе өчен - 0 граждан тавыш бирде.
"тоткарланучылар" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнары җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Мәсәде авыл җирлегенең Мәсәде авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Мәсәде авыл җирлегенең Мәсәде авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары булган гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча 500 сумнан узара салым акчасы җыю белән ризамы:

1. Су белән тәэмин итү системаларын, төзүне һәм ремонтлауны һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су үткәрү челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау, суны анализлау).

2. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен тоту һәм ремонтлау);

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (хуҗасыз йортларны сүтү, агачлар кисү, массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерү).

4.Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау).

3. Әлеге карарны Мәсәде авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга - http://aktanysh.tatar.ru .

Мәсәде авыл җирлеге башлыгы И.Т.Гатин